ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.12.2019 Олы Кайбыч ав. № 518

2020 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга расларга:

- Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын, балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативлары (1 нче кушымта)
- Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын, балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә (2 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Финанс бюджет палатасына:

гомуми белем бирү оешмаларын, балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативлары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә (әлеге карарның 1 пунктында расланган).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Биккулова А.Ә.га йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2019 елның 03.12 518 номерлы карарына 1нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын, балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативлары**

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка (елга, сум) | автотранспорт чарасы узган бер километрга ставка, сум |
| КАВЗ | 116398 | 37,42 |
| ПАЗ | 116656 | 37,35 |
| ГАЗ «Газель» | 110767 | 30,41 |
| УАЗ | 110314 | 29,04 |
| FIAT | 110057 | 27,47 |
| Peugeot Boxer | 110572 | 27,11 |
| Ford Transit | 110829 | 30,37 |

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2019 елның 03.12. 518 номерлы карарына 2нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын, балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Әлеге Нигезләмә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын, балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү механизмын билгели (алга таба - муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм автотранспорт чараларының факттагы узган юлы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен Кайбыч муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының фактик узган юлы турындагы мәгълүмат автотранспорт чарасының расланган паспорты кысаларында эшләнгән автотранспорт чарасының хисап елында фактик узышы буларак Татарстан Республикасында аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү.

2.1. $i$ муниципаль берәмлегенә муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

монда:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - $m$ модельле автотранспорт чараларының факттагы узган юлы;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру нормативының бер километрга, бер сумга ставкасы;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда бер автотранспорт чарасына ташуны оештыру бәясе нормативының ставкасы, сум;

$M_m$ - $m$ модельле автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе исеме;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.